КАРАР (РЕШЕНИЕ)

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге составына керүче Шәмәрдән торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

21.11.2025 ел № 1

«Гавами хакимиятнең бердәм систетемасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьяьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Тимершылык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Советының 17.12.2021 елның 26 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында" карарына таянып 2025 елның 17 нче, 18 нче, 19 нчы, 20 нче ноябрь көннәрендә узган гражданнар җыенында «2026 нчы елда Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Шәмәрдән торак пунктында балигъ булган, Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге составына керүче Шәмәрдән торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,0 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме? " мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (туфрак эшкәртү, комлы нигез салу, юл кырыйларын төзү, су үткәрү торбаларын урнаштыру, Шәмәрдән торак пунктындагы килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Торак пункт территориясен төзекләндерү (Шәмәрдән торак пунктында спорт һәм балалар мәйданчыкларын ремонтлау);

- Ремонт, коймалар кору, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү (Шәмәрдән торак пунктындагы зират территориясен төзекләндерү);

- Тукталыш комплексларын ремонтлау, сатып алу һәм урнаштыру (Шәмәрдән т.п. тукталыш комплексларын ремонтлау, сатып алу һәм урнаштыру).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган, гражданнар җыенына 4303 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 2274 кеше тавыш бирүдә катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 2225 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 49 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге составына керүче Шәмәрдән торак пунктында халык җыенын үткән дип таныргa, халык җыены нәтиҗәләре – чын мәгънәсендә дип таныргa.

1. «2026 нче елда Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Шәмәрдән торак пунктында Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге составына керүче Шәмәрдән торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,0 сум күләмендә үзара салым кертүгә” һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге киләсе мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме? - дигән сорау буенча:

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (туфрак эшкәртү, комлы нигез салу, юл кырыйларын төзү, су үткәрү торбаларын урнаштыру, Шәмәрдән торак пунктындагы килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Торак пункт территориясен төзекләндерү (Шәмәрдән торак пунктында спорт һәм балалар мәйданчыкларын ремонтлау);

- Ремонт, коймалар кору, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү (Шәмәрдән торак пунктындагы зират территориясен төзекләндерү);

- Тукталыш комплексларын ремонтлау, сатып алу һәм урнаштыру (Шәмәрдән т.п. тукталыш комплексларын ремонтлау, сатып алу һәм урнаштыру).

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/shemordan адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында
рәислек итүче,
Шәмәрдән авыл
җирлеге башлыгы А.К.Валиев